## Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе *Р.З. Закировның* сәламләү сүзе

**Газиз милләттәшләр!**
**Хөрмәтле коллегалар!**

Мин сезне Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән кайнар сәламлим. Безнең шушылай тарихи ватаныбыз башкаласы Казанда очрашуыбыз тирән мәгънәгә ия. Сез беләсез, XX гасыр азагында татар тормышы шактый җанланды, милләтебез хәрәкәткә килде. Илдәге демократия җилләре татарны да уятты, халыкка үз хокукларын якларга мөмкинлекләр бирде. Ә бу мәсьәлә гасырдан-гасырга татар өчен мөһим проблемаларның берсе булып тора. Юкка гына бөек Тукай «Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?/ Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук», – дип язып калдырмаган бит. Шушы хокуклар өчен көрәш нәтиҗәсе буларак, Татарстан дәүләтчелеге дә үсте, ул яңа статуска ия булды, аның мөмкинлекләре артты. Әлбәттә, моның нигезендә 1990 елның 30 августында кабул ителгән Мөстәкыйльлек Декларациясе ята. Ул вакытта Татарстан кичергән үзгәрешләрне мин күп гасырлы татар халкы тарихының иң мөһим вакыйгаларыннан берсе дип бәяләр идем. Безнең бүгенге очрашуыбызны да шул вакыйгаларның дәвамы дип атасам – ялгышмам.

Татар гомер-гомергә зыялы, укымышлы халык булган. Без хаклы рәвештә үзебезнең меңъеллык язма әдәбиятыбыз, китап культурабыз белән горурланабыз. Идел Болгарстанында X гасырда Ислам динен кабул иткәч, мәчетләр каршында мәктәп-мәдрәсәләр эшли башлый, халык дин сабагы аша укырга-язарга өйрәнә. Һәм динле, мәгърифәтле булу безнең халкыбыз өчен яшәү рәвешенә әверелә. Бу Идел Болгарстанында да, Алтын Урда дәүләтендә дә, Казан ханлыгында да шулай булган. Әлбәттә, мөстәкыйль дәүләтчелекне югалткач, татар тормышы шактый катлаулана. Әмма, иң авыр шартларда да татар халкы мәчетләрен, мәктәп-мәдрәсәләрен саклап калырга тырыша. Атаклы алман галиме, Казан университеты профессоры Карл Фукс үзенең «Казан татарлары» исемле хезмәтендә «татарлар күп кенә Европа халыкларыннан да белемлерәк, укый-яза белми торган татарны милләттәшләре һич хөрмәт итмиләр», – дип XIX гасырда ук язып калдырган.

Әлбәттә инде, патша Русиясе шартларында татарларга фән белән шөгыльләнү шактый кыен була, әмма XVIII йөздән XIX йөзгә күчкәндә безнең халкыбыз вәкилләреннән дә күренекле гыйлем ияләре үсеп чыга. Шуларның берсе дин галиме Габденнасыйр Курсави була. Ул мөселман дөньясы өчен революцион фикерләр әйтә: «Заманы иҗтиһады монкарыйз, ягъни, иҗтиһад капкасы һәркем өчен ачык». Бу очракта иҗтиһад сүзен иҗат сүзенең синонимы дип кабул итәргә кирәк. Соңгырак XIX гасыр уртасында татар тарихы фәненә нигез салучы олуг галим Шиһабетдин Мәрҗани фикер мәйданында пәйда була. Ул безнең милли тарихны өйрәнүгә чын гыйльми юнәлеш бирә. Ә инде аның шәкертләре Хөсәен Фәизханов, Каюм Насыйри һәм башкалар татар фәненең мәйданын тагы да киңәйтәләр. Шунысын әйтергә кирәк, Шиһабетдин Мәрҗанине, формаль фәнни дәрәҗәләре булмаса да, Русия тарих һәм шәркыять гыйлеме җәмгыятенә кабул итәләр, аны университет галимнәре даими рәвештә

үзләренең фәнни эзләнүләренә җәлеп итеп торалар. Сез беләсез, 1905 елгы рус революциясенә хәтле татарларны Русия югары уку йортларына кабул итмиләр. Әмма шуңа да карамастан, татарлардан да чит ил университетларына барып укучылар шактый була. Әлбәттә, болар – хәлле кешеләр балалары. Әйтик, Сорбоннада лекцияләр тыңлаган Йосыф Акчура Сембер тукыма фабрикантлары Акчуриннар нәселеннән. Шулай ук Сорбоннада белем алган Садри Максуди да Казан артының хәлле, укымышлы татар гаиләсеннән. Сорбоннада белем алган математика профессоры Сара Шакулова да Касыйм татарларының хәлле нәселеннән.

Гомумән, XX гасыр башы татар тарихында аерым урын алып тора, ул чорны юкка гына татар ренессансы дип атамаганнар. Карагыз, нинди көчле милли күтәрелеш була ул дәвердә. Нәкъ шул чорда татар заманча милләт булып оеша, аның әдәби теле, яңа мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате, матбугаты барлыкка килә. Шул чорда татар мәгариф системасы көчле үсеш ала, ысулыҗәдит нигезендә мәктәп-мәдрәсәләр заманча белемле кешеләр әзерли башлый. Әйтик, атаклы «Мөхәммәдия», «Хөсәения», «Галия», «Иж-Буби», «Рәсүлия» мәдрәсәләре күп фәннәрне гимназия программалары нигезендә укытып, үз чорының иң дәрәҗәле уку йортларына әвереләләр. Һәм әйтергә кирәк, шул системада укыган татарлардан чын галимнәр, фән кешеләре чыга башлый. Ил күләмендә танылган зур галимнәр Хәмит Мөштәри, Гыйлем Камай, Шәүкәт Хәбибуллин, Мөхәммәт Гайнуллин, Мидхәт Мөхәррәмов, Ибраһим Нуруллин һәм башкалар.

Совет чоры да татар өчен гади булмады, әмма шунысын танырга кирәк: ул елларда татарларга югары белем ишекләре киң ачылды, милли мәдәният, сәнгать көчле үсеш юлына басты. Фән өлкәсендә дә татарлар лаеклы урын алды. Нәкъ шушы елларда дөнья фәнендә үзләрен таныткан татарлардан Роальд һәм Ренад Сәгъдиевләр, Кев Миннуллин, Наил Сәхибуллин, Альберт Галиев, Данияр Мөштәри, Марат Арсланов һәм башкаларны атап була. Совет чорының тагы бер үзенчәлеге турында әйтергә кирәк: атом, космоска кагылган ябык тематикада бик күп татар галимнәре эшләде. Аларның күбесенең исемнәре әле дә киң катламнарга билгеле түгел. Димәк, илнең интеллектуаль потенциалын булдыруда татар өлеше гаять зур. Шаяртып булса да әйтим инде, татар үзе космоска очмаса да, шушы өлкәдә татар галимнәре булмаса, илнең авиация-космонавтика тармагында шундый зур уңышлары булыр идеме икән?

Гомумән, халкыбыз олы шәхесләргә, талантларга гомер-гомергә бай булды. Соңгы елларда без мондый шәхесләребезне танытырга, олыларга өйрәндек. Шуның белән бергә безнең үзебездә дә милләтебез өчен горурлык хисләре артты. Без бүген авыз тутырып «татар дөньясы» дип сөйли алабыз икән, монда һәр милләттәшебезнең, кайсы җирдә яшәвенә карамастан, үз өлеше бар. Шуңа да безгә һәр татар кешесе кадерле, ә инде милләтнең интеллектуаль потенциалын тәэмин иткән галимнәр бигрәк тә. Татар дөньясының бердәмлеген, көчен раслап бу залга җыелган галимнәребезгә Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән олы рәхмәтләребезне җиткерәм.

Бүген илдә татар факторы бар икән, бу, һичшиксез, Татарстан белән татар милләте бердәмлеге билгесе. Көчле Татарстан булмаса, татар дөньясына да авырга туры килер иде.Татарстан да, шөкер, бүген дөньяга сибелгән татар халкына таяна ала. Мондый бердәмлек безнең алдыбызда яңа мөмкинлекләр ача. Галимнәр форумы да шушы мөмкинлекләр турында уртага салып сөйләшү максатыннан уздырыла.

Ә бүген милләтебез алдында торган проблемалар шактый күп һәм, әйтер идем, бик куркыныч тенденцияләр дә күзәтелә. Бигрәк тә мәгариф, белем бирү өлкәсендә. Иң куркынычы – аны гасырлардан килгән тамырларыннан аеру сәясәте алып барыла. Балалар-

ны ата-бабаларыбыз рухи мирасында тәрбияләүне бернинди модернизация, электрон мәктәпләр, компьютерлар белән алыштырып булмый. Туган теленнән мәхрүм ителгән бала ул тамырлары киселгән гөлне хәтерләтә. Бу мәсьәләнең чишелешен галимнәрдән башка табу мөмкин түгел. Бүген заманча технологияләр туган телне дөньяның теләсә кайсы җирендә яшәп тә өйрәнү мөмкинлеге бирә. Әйе, туган телдә укыту – ул дәүләт эше, бу Конституциядә шулай билгеләнгән. Ләкин елдан-ел җимерелә барган татар мәгарифенең нинди хәлдә булуын истә тотып, без туган телне өйрәнү мәсьәләсен җәмәгатьчелек аша хәл итәргә мәҗбүр. Шуңа да без бүген Интернетта татар социаль челтәрен булдыру өстендә эшлибез. Бөтендөнья татар конгрессы нигезендә оештырылачак бу челтәр татар халкын берләштереп кенә калмас, ул аңа мәгариф, аң-белем тарату өлкәсендә дә, бердәм мәгълүмат яссылыгын булдыруда да уңай шартлар тәэмин итәчәк. Бу яңа технологияләр белән бергә бездән заманча фикерләү дә таләп ителә. Шуңа да татар галимнәре бу эштән читтә тормасыннар иде, монда һәркемгә үзенең интеллектуаль көчен куллану мөмкинлеге бар.

XXI гасыр дөньядагы һәр милләт алдында катлаулы сынаулар куя. Киләчәктә дә бербөтен милләт булып сакланып үсәр өчен халыкның барлык интеллектуаль көчләренә бергә туплану зарур, шулай булганда гына без әлеге сынауларны уңышлы уза алырбыз. Дөньяга сибелгән татар халкының дүрттән бер өлеше генә Татарстанда яши, шуңа да карамастан, без һәрдаим барлык милләттәшләрнең ярдәмен, теләктәшлеген тоеп яшибез. Ә инде галимнәргә, фән әһелләренә килгәндә, алар кайсы илдә дә дәрәҗәле, абруйлы кешеләр, аларның теләсә кайсы җәмтыятьтә тәэсире – йогынтысы көчле. Шулай булгач, сез – тарихи ватаныбыз Татарстанның иң ышанычлы терәге, сезнең дөньяда булуыгыз гына да – милләтебезгә нык таяныч һәм үсеш нигезе. Бүгенге катлаулы шартларда гыйльми фикер аша һәм фәнни нигездә милләт проблемаларын хәл итә алсак, уңышка ирешербез. Бергә булыйк, бердәм булыйк.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!